ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасында демография сәясәтен гамәлгә ашыру турында

«Хөкүмәт сәгате» кысаларында Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Э.Ә. Зарипованың Татарстан Республикасында демография сәясәтен гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасында демография сәясәтен гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына республиканың демография потенциалын булдыручы балалы гаиләләр һәм репродуктив яшьтәге гражданнар мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләрне җайга сала торган законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасында туучылар санын арттыру буенча региональ программа (чаралар планы) һәм «Гаилә» илкүләм проектының «Ана булуны һәм балачакны яклау» федераль проектын гамәлгә ашыру кысаларында расланган «Татарстан Республикасында ана булуны һәм балачакны яклау» региональ программасы чараларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны дәвам итәргә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Республика халкының медицина ярдәменнән файдалана алуын тәэмин итү мәсьәләләрен даими тикшереп торырга.

4.2. «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе белән берлектә ярдәмче репродуктив технологияләр (ЭКО) кулланып күрсәтелә торган медицина ярдәменнән файдалана алуны һәм аның нәтиҗәлелеген тәэмин итү чараларын күрергә.

4.3. Медицина хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән йөкле хатын-кызларга Татарстан Республикасында гражданнарга һәм балалы гаиләләргә күрсәтелә торган ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне дәвам итәргә.

4.4. Хатын-кызларга бала туганчы һәм бала туганнан соң медицина психологлары тарафыннан консультацияләр бирүне тулы күләмдә тәэмин итәргә.

4.5. Йөклелекне өзү буенча медицина хезмәте күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән йөкле хатын-кызларга мотивацияле анкеталар тутыруны үткәрү эшен дәвам итәргә, шулай ук хатын-кызларда репродуктив сайлау очрагында балалар тууга уңай фикерләр булдыру өчен сөйләм модульләрен куллануны дәвам итәргә.

4.6. Киләчәктә балалар туу өчен уңайлы шартлар тудыру өчен хатын-кызларга бала туганнан соң ярдәм итү системасын, патронажны да кертеп, камилләштерүгә юнәлдерелгән мәсьәләләргә аерым игътибар бирергә.

4.7. Репродуктив сәламәтлекләрен саклап калу максатларында балигъ булмаганнарга (15 – 17 яшь) профилактик медицина караулары һәм репродуктив яшьтәге гражданнарга (18 – 49 яшь) диспансеризация үткәрүне дәвам итәргә.

4.8. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән берлектә барлык яшьтәге гражданнарда сәламәт яшәү рәвешен алып баруга омтылыш булдыру эшен дәвам итәргә.

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Татарстан Республикасында «Гаилә» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү эшен дәвам итәргә.

5.2. Авыр тормыш яисә кризис хәлендә калган йөкле хатын-кызларга, шул исәптән йөкле балигъ булмаганнарга, социаль хезмәт күрсәтүне һәм социаль ярдәм итүне оештыру эшен көчәйтергә.

5.3. Студент гаиләләренә, яшь, аз керемле, күпбалалы, инвалид балалары булган гаиләләргә һәм ялгыз ата-аналарга ярдәм итү максатларында яңа туган балалар өчен беренче чиратта кирәк булган предметларны прокатка бирү пунктлары челтәрен киңәйтү мөмкинлеген карарга.

5.4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә аз керемле студент гаиләләрен «Социаль няня» хезмәте белән тәэмин итүне арттыру мөмкинлеген карарга.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

6.1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм Балаларның һәм яшьләрнең «Беренчеләр хәрәкәте» гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте Татарстан Республикасы региональ

бүлеге белән берлектә балаларны һәм яшьләрне традицион гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруга, аларда гаилә кыйммәтләренә карата позитив мөнәсәбәт булдыруга, буыннар элемтәсен ныгытуга, сәламәт яшәү рәвешен һәм физик культураны пропагандалауга юнәлдерелгән чараларда катнашуга җәлеп итү эшен көчәйтергә.

6.2. Балалар һәм яшьләр белән алкоголь продукциясе һәм спиртлы продукция, никотинлы продукция, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр куллануны профилактикалауга юнәлдерелгән тематик чаралар үткәрү эшен активлаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

7.1. Урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларының укыту планнарына гаилә институтын ныгыту, җәмгыятьтә традицион Россия рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен яклау, саклау һәм аларны алга этәрү максатларында ата-аналарның социаль рольләрен, җаваплы репродуктив тәртип моделен булдыру, йөклелекне ясалма өзүнең хатын-кыз организмы өчен тискәре нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирү буенча программаларны кертү мәсьәләсен карарга.

7.2. Яшь студент гаиләләренә һәм яшь укытучылар гаиләләренә ярдәм һәм комплекслы ярдәм итү системасын булдыру эшен активлаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына социаль ипотека системасында торакка хокукны гамәлгә ашыручы гаиләләргә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда республика дәүләт ярдәме бирү тәртибен камилләштерү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

9. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм сәнәгатьчеләре ассоциациясе (эш бирүчеләрнең региональ берләшмәсе), Татарстан Республикасы кече һәм урта бизнес предприятиеләре ассоциациясе, Татарстан Республикасы һөнәр берлекләре федерациясе белән берлектә Татарстан Республикасында эш бирүчеләргә эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итүнең корпоратив социаль программаларын гамәлгә ашыруны дәвам итү кирәклеге турында мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

10. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

10.1. Гаилә ялы өчен конструктив мохит буларак җәмәгать пространстволарын үстерүгә юнәлдерелгән программаларны гамәлгә ашыру эшен активлаштырырга.

10.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе белән берлектә традицион гаилә кыйммәтләрен пропагандалау, ата-ана статусын күтәрү, җәмгыятьтә гаиләнең позитив образын булдыру максатларында чаралар оештыру эшен дәвам итәргә.

11. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына территорияләрне комплекслы үстерү, балалар уен һәм спорт мәйданчыкларын, парк зоналарын һәм гаилә ялының башка объектларын төзекләндерүне дә кертеп, шулай ук социаль инфраструктура объектларыннан һәм җәмәгать транспортыннан файдалана алуны тәэмин итү эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

12. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына, күпбалалы булуны популярлаштыруга, балалы гаиләнең абруен күтәрүгә, шулай ук халыкта репродуктив сәламәтлеккә җаваплы мөнәсәбәт һәм гаиләне аңлы рәвештә планлаштыруны булдыруга аерым игътибар биреп, традицион гаилә кыйммәтләрен ныгытуга юнәлдерелгән чараларны системалы мәгълүмати яктыртуны оештыруны тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетына ел саен үткәрелә торган «Минем шәҗәрәм» республика генеалогик тикшеренүләр конкурсын үткәрүне дәвам итүне тәкъдим итәргә.

14. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
692-VII ДС